МИНИСТЕРСТВО ТРАНСПОРТА
И ДОРОЖНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТРАНСПОРТ ҺӘМ ЮЛ
ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ

**БОЕРЫК** **ПРИКАЗ**

от “24” 09.2025 № 62

Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының 2024 елның 1 октябрендәге 44 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә гомуми таләпләр хакында» 2016 елның 6 маендагы 393 номерлы карарына үзгәрешләр кертүгә бәйле рәвештә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибен раслау турында» 2024 елның 1 октябрендәге 44 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктта:

4.1 пунктчада «Хисаплылыктан өземтә» сүзләрен «Белешмә» сүзенә алмаштырырга;

4.2 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2. Татарстан Республикасы бюджетына Россия Федерациясе Бюджет кодексының 160.1 статьясы нигезендә билгеләнгән бюджетка түләүләр, пенялар һәм алар буенча штрафлар буенча дебитор бурычларын түләтүнең бюджет керемнәре администраторы вәкаләтләрен гамәлгә ашыру регламентында каралган түләүләр буенча бурычларны түләтүне тәэмин итүдә күрелгән чаралар турында финанс бүлеге

тарафыннан әзерләнгән Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы белешмәсе;»;

4.3 пунктчаның алтынчы абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«аның нигезендә бюджет керемнәре администраторы, шул исәптән аны түләтү буенча билгеләнгән срок тәмамлануга бәйле рәвештә дә, бюджетка түләүләр буенча бурычларны түләтү мөмкинлеген югалта торган штраф яки суд акты рәвешендә хөкем ителгәннәргә карата амнистия яки кичерү турында акт (Тәртипнең 2 пунктының 2.4 пунктчасында күрсәтелгән очракта);»;

4.3 пунктчага түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«гражданинның судтан тыш банкротлык процедурасы тәмамлануы турында Банкротлык турындагы белешмәләрнең бердәм федераль реестрыннан белешмәләр булган документ (Тәртипнең 2 пунктының 2.2 пунктчасында күрсәтелгән очракта).».

2. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр Ф.М. Хәнифов